УДК 908
EDN LYBKTS
DOI 10.24412/2073-7475-2026-3-98-108

# Төбәк тарихын өйрәнүче Г. Г. Хисамиев хезмәтләре

*И. К. Заһидуллин,*

*Татарстан Республикасы фәннәр Академиясенең Исламны өйрәнү үзәге, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# Works of local historian G. G. Khisamiev

*I. K. Zagidullin,*

*Center for Islamic Studies, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**
В статье анализируются научно-популярные труды кандидата технических наук Галима Гильмутдиновича Хисамиева, автора десяти книг по истории родной деревни Степные Шенталы Алексеевского района Республики Татарстан. Результатами его изысканий являются, главным образом, тематические издания, освещение и интерпретация событий, происходивших в относительно небольшие хронологические рамки. Достоинством объемных изданий Г. Г. Хисамиева следует признать публикацию наряду с собственным исследовательским текстом большого количества исторических источников, выявленных из фондов Государственного архива Республики Татарстан, Национального архива Республики Башкортостан, Российского государственного архива древних актов и воспоминаний представителей старшего поколения и современников, впервые вводимых в научный оборот. Исследовательский подход, основанный на микроисторическом анализе, позволил автору подготовить научно-популярные монографии в документах, в которых по-новому раскрываются внутренний мир татарской деревни, мотивации и поступки сельских жителей, их надежды и чаяния. В статье делается вывод о том, что книги Г. Г. Хисамиева являются феноменом в современном татарском краеведении и демонстрируют высокий потенциал архивных фондов для детальной реконструкции различных аспектов жизнедеятельности сельских населенных пунктов и их жителей.

**Abstract**
The article analyzes the accessible scholarly works of Galim Gilmutdinovich Khisamiev, author of ten books on the history of his native village Stepnye Shentaly (Alekseevsky District, Republic of Tatarstan). The results of his research are primarily thematic monographs focusing on events within a compact timeframe. A particular strength of Khisamiev's lengthy publications lies in integrating a substantial body of archival materials with his own narrative. These sources

were identified in the funds of the State Archive of the Republic of Tatarstan, the National Archive of the Republic of Bashkortostan, the Russian State Archive of Ancient Acts, as well as in memoirs of older generations and contemporaries being introduced into academic discourse for the first time. His microhistorical approach enabled the author to prepare document-based monographs that offer new insights into the inner world of the Tatar village, the motivations and actions of its rural residents, along with their hopes and aspirations. The article concludes that G. G. Khisamiev's books represent a significant phenomenon in modern Tatar regional historiography (kraevedenie) and demonstrate the high potential of archival collections for detailed reconstruction of various aspects of life in rural settlements.

**Ключевые слова**
Татарское краеведение, деревня Степные Шенталы, отпавшие в ислам крещеные татары, мечети, сельское хозяйство, колхозы.

**Keywords**
Tatar local lore (kraevedenie), Stepnye Shentaly village, baptized Tatars who converted to Islam, mosques, agriculture, collective farms (kolkhozes).

Соңгы берничә дистә елда Татарстанда төбәк тарихын өйрәнү өлкәсендә зур уңышларга ирешелде. Бу уңышлар, беренче чиратта, авыл тарихларына багышланган китап-мәкаләләр санының нык артуы һәм аларны язучылар саны ишәю белән билгеләнә. Зур казаныш буларак, халык хуҗалыгының төрле өлкәләрендә эшләп лаеклы ялга чыккан төбәк тарихчылары сафына күп санлы урта яшьтәге һәм, бигрәк тә, яшь буын вәкилләренең өстәлүен әйтергә кирәк. Бу исә тупланган тәҗрибәне дәвам итәргә мөмкинлек бирә. Шунысы да мөһим: төбәк тарихчыларының районнарда дәрәҗәсе күтәрелде, алар бүген төбәк фәнни-гамәли конференцияләрендә мәйдан тота.

Иң сөендергәне – төбәк тарихы буенча басылган китапларның сыйфаты яхшыра баруы. Бу үзенчәлекле өлкәгә үтеп кергән базар мөнәсәбәтләре басмаларның сыйфатын яхшыруга хезмәт итә. Һәр районда диярлек шушы як авыллары тарихын язып дан алган һәм аларны язуга специальләшкән шәхесләр уңышлы эшләп килә. Алар авыл халкы яки аерым кешеләр тарафыннан бирелгән заказларны тырышып башкаралар.

Китапларның сыйфатын күтәрүгә сәбәп булган яңа күренеш дип кайбер энтузиастларның китап басылып чыкканнан соң да эзләнүләрен дәвам итеп, яңа чыганаклар табып һәм аларны шәрехләп, теманы киңәйтеп һәм тирәнәйтеп, хезмәтләренең икенче, төзәтелгән һәм тулыландырылган, басмаларын нәшер итүләрен әйтү мәслихәт.

Сыйфат үзгәрешләренә туган авыллары тарихларын язуга югары уку йортларында яки фәнни-тикшерү институтларында эшләүче галим-голәмәнең алынуы бу мәдәни-эзләнү хәрәкәтенә уңай йогынты ясады. Өйрәнелә, тикшерелә торган проблеманы хәл итү методикасын үзләштергән, эзләнүләр алып бару тәртибен белгән, системалы фикерләүгә һәм фәнни телдә язу стиленә ия бу фидакарь затлар төбәк тарихы дигән яңа өлкәне бик уңышлы үзләштерделәр.

Шушы төркем вәкилләреннән, туган авылы тарихын язуга алынып, зур уңышларга ирешкән күренекле шәхесләрнең берсе – доцент, техник фәннәр кандидаты Хисамиев Галим Гыйльметдин улы.

Галим Гыйльметдин улы 1958 елның 5 ноябрендә Татарстанның хәзерге Алексеевск районы Кыр Шонталасы авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан химия-технология институтында, аннары аспирантурада белем алган. 1991 елда кандидатлык диссертациясен уңышлы яклаган. Г. Г. Хисамиев – Казан төзелеш һәм архитектура (1990-2000), Казан авыл хуҗалыгы (1995-2000) институтларында, чирек гасырга якын (2000-2023) Казан медицина университетының гомуми һәм органик химия кафедрасында студентларга белем биргән.

Төп хезмәт урыныннан тыш, Г. Хисамиев «Фәнни Татарстан» журналында редактор-тәрҗемәче (1997-2001), «Фән һәм тел» фәнни-хәбәри журналының редакторы (1989-2014) буларак та хезмәт куя.




Әйтергә кирәк, Г. Г. Хисамиев – Татарстан югары уку йортларында татарча белем бирүне башлап җибәрүче, фән өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешкән галимнәребезнең берсе. Ул – 250 артык фәнни хезмәт авторы, сигез авторлык шәһадәтнамәсе һәм ике ачыш ясау хакында патент иясе. 1990-2000 еллар башында татар телен фән һәм югары уку йортында укыту теле итү өчен тырышып, «Химический русско-татарский толковый словарь» (2004), хезмәттәше Р. С. Сәйфуллин белән «Толковый словарь-справочник по физике, химии и химической технологии на русском, татарском и английском языках» (1996) аңлатмалы сүзлекләр төзегән укытучы-галим. Аның югары уку йортлары студентлары өчен язылган «Гомуми химия» (1998) дәреслеге һәм «Гомуми химия: мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы» (1999) исемле уку әсбабы, шулай ук абитуриентлар һәм укытучыларга атап эшләнгән берничә дистә кулланмалары бар.

Авторның 2015 елда дөнья күргән «Гөләйза кыйссасы» исемле беренче китабын эчтәлегенә карап микротарихи анализга нигезләнгән һәм документларда бирелгән монография дип атау урынлы булыр. Китап ике кисәктән гыйбарәт.

Хезмәтнең беренче кисәге тулысынча архив чыганакларына нигезләнеп язылган, ул Казан губернасы Чистай өязенең Кыр Шонталасы авылында көн күргән, мөселманлыкка чыккан «яңа чукындырылганнар» гаиләсеннән булган өч бала анасы Гөләйза исемле хатынның шушы «җинаяте» өчен тарган газаплары һәм тетрәндергеч язмышы турында. Гөләйзаның тормышындагы һәрбер вакыйга автор хикәяләве, архив чыганагының кайдан алынганын төгәлләштермичә генә, шушы хактагы губерна хакимияте, мәхкәмә, полиция һәм Рус православие чиркәве институтларының эш кәгазьләре текстлары белән «ныгытылып» барыла[1]. Ул да түгел, беренче кисәккә кушымталар рәвешендә Гөләйзага кагылышлы бер төркем документлар урнаштырыла[2]. Шул рәвешле, автор бу четрекле һәм

катлаулы теманы ачуны, зур күләмдәге архив документларын кулланып, уңышлы хәл итә.

Хезмәттә Г. Исхакыйның «Зөләйха» пьесасының прототибы тарихи персонаж Гөләйза булырга мөмкин дигән фикер дә әйтелә[3].




Билгеле булганча, шушы китап һәм анда бирелгән документлар белән рухланып, күренекле татар язучысы Ф. Бәйрәмова 2018 елда «Гөләйза» исемле тарихи роман яза, бу шәхесне бөтен татар дөньясына таныта.

Бу темага әйләнеп кайтып, Г. Хисамиев 2021 елда «Гөләйза кыйссасы» китабының икенче басмасын нәшер итте. Монда автор, төп сюжетны төгәлләштереп яктыртканнан соң, Г. Исхакыйның «Зөләйха» пьесасы героеның прототибы Гөләйза дигән фикерне ныгытып, китабына кушымта рәвешендә язучы Ф. Бәйрәмованың ике язмасын урнаштыра[4].

Китапның икенче «Татар хатыны ниләр күрми» исемле кисәген[5] язуның максаты дип автор Кама аръягы мөселман хатын-кызларының гаиләдәге хокукый хәлен яктыртуны күрсәтә[6]. Монда Чистай һәм Спасс өязләре авылларыннан Мәхкамәи шәргыягә ирләренең җәберләүләренә, мыскыл итүләренә түзә алмыйча һәм башка сәбәпләр белән аерылышуны сорап язган гаризалар нигезендә ачылган эшләр яктыртыла. Китапта бәян ителүче 15 тарихның 14-е шундый татар хатын-кызлары язмышын сурәтли. Автор шәрехләвеннән соң рәсми документларның текстлары китерелә, кайбер русча һәм муллалар язган татарча кәгазьләрнең копияләре яки текстлары урнаштырыла. Киң планда караганда, бу материалларда Россия империясендә гаилә мөнәсәбәтләре өлкәсендәге шәригать кануннары һәм хөкем чыгару барышы тасвирлана. Бу күңелсез вакыйгаларны тикшергәндә һәм алар буенча карар кабул иткәндә һәрчак диярлек хатын-кыз ягын алган Мәхкамәи шәргыя казыйлары, руханилар, авылдашларының гамәлләре, низаглы йортта ир белән хатын, туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр – барысы да XIX-XX йөз мөселман татар крестьяннарының әхлагы һәм тәрбиясе турында тирән уйлануларга этәрә һәм фикерләү өчен бик күп яңа материал бирә.

Шул рәвешле, Г. Хисамиевның төбәк тарихын язудагы беренче тәҗрибәсе аның башка хезмәтләренең дә юнәлешен билгели. Автор киң планда, архив материалларына нигезләнеп һәм аларны китабында киң кулланып язуны үзенең төп кануны итә. Моннан тыш, авыл тарихын язуда үзәккә аерым проблеманы (соңрак – аерым тарихи чорларны) өйрәнү юлын сайлый. Болай иркенләп шәрехләү, язу авторга еш кына авыл тарихының башка төбәк тарихчылары китапларында читтә калган чыганакларын барлап, зур күләмдәге эксклюзив тарихи материалны фәнни әйләнешкә кертүгә мөмкинлек бирә.

«Кыр Шонталасы авылы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (тулы вариант)» исемле күләмле басма – Г. Хисамиевның сигез еллык эзләнүләр нәтиҗәсе – классик хезмәт дәрәҗәсендә эшләнгән китап дип бәяләнергә хаклы.

Китапта шәҗәрәләр бердәм структурага кертелеп, нәселне нигезләүче кешеләрдән башлап, тармаклап һәм буынлап-буынлап, архивларда табылган барлык төр статистик һәм башка төрле чыганаклар (кешеләрдән сораштыру, каберташларын уку һ. б.) нигезендә төзелгән. Басманың керешендә кыз биреп,

килен төшереп туганлашып яшәгән күрше авыллар атала, шәҗәрәләрне уку тәртибе аңлатыла. Әйтик, авылда мөселманнар һәм «яңа чукындырылганнар» яшәүне исәпкә алып, автор шәҗәрәләрдә чукындырылган һәм мөселманча яшәгән кешеләрнең исем-фамилияләрен русча һәм татарча, татарча исемнәрен билгели алмаган очракта, русча исемнәрен калдыруын, метрикә кенәгәләрендәге «никахланды» сүзен, аңларга җайлырак булсын өчен, курсив белән язуын, җәя эченә «вәкил» сүзен өстәвен әйтеп үтә; еш кабатлана торган сүзләрне кыскарту вариантларын китерә[7]. Китап ахырында исемлек күрсәткече урнаштыру – кирәкле мәгълүматны тиз табарга, фамилия буенча күпләрнең нинди тармак/нәселдән икәнен һәм алар турында мәгълүматның нинди параграфта урнаштырылганын ачыкларга ярдәм итә. Шушы ук максаттан чыгып, төп текстта исемнәре телгә алынган кешеләрнең нинди бүлектә бирелүен табу өчен сылтама биреп барыла.

Китапның башка бүлекләрендә үткәрелгән ревизия материаллары (1762/1763, 1816, 1850, 1858 еллар); Краснояр авылы православие чиркәве руханиеның тәүбә-истигъфар булучыларны теркәү кенәгәләре (1798, 1799, 1801, 1803-1806, 1813, 1831, 1838 еллар), христианлыктан исламга күчүчеләрнең исемлекләре (1851, 1860, 1861 еллар), исламга кайтуны рәсмиләштерү буенча мөрәҗәгать итүчеләр исемлеге (1893, 1896 еллар), мәхәллә халкының туу, үлү, никахлашу һәм аерылышуы теркәлгән метрикәләр (1833, 1865, 1867, 1868, 1871, 1873-1886, 1888-1917, 1921 еллар) язмалары, Совет чоры документларыннан Краснояр авыл советы рәисе тарафыннан төзелгән Кыр Шонталасында ачлыктан интегүче гаиләләр һәм гаилә әгъзалары исемлеге (1921 ел), хуҗалык кенәгәсе (1955-1957 еллар) бирелгән. Православие чиркәве руханилары алып барган метрикә кенәгәләре булмавын исәпкә алмаганда (күрәсең, шәҗәрә төзү өчен тәүбә-истигъфар булучыларны теркәү кенәгәләрендә тупланган мәгълүмат җиткән) китапта шәҗәрә төзергә ярдәм итүче барлык төр чыганаклар да бирелгән дип әйтергә мөмкин.

Шулай ук китапта урын алган кайбер архив документларының фотокүчермәләре, имән агачы рәсеме рәвешендә эшләнгән шәҗәрәләр дә игътибарга лаек. Басмада соралып торган нәсел тамгаларын автор 2025 елда нәшер ителгән «Кыр Шонталасы авылының борынгы тарихы» китабында китерә[8].

Шул ук 2021 елны «Кыр Шонталасы авылы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (кыскартылган варианты)» исемендә дөнья күргән басмада югарыда карап үткән китаптан нәсел шәҗәрәләре турындагы беренче (китап) кисәге урнаштырылган[9].

Автор «Кыр Шонталасы тарихы» сериясеннән «Гаилә шәҗәрәсе» исемле китап та нәшер итеп, нәсел шәҗәрәсен ничек төзергә мөмкин икәнлеген күрсәтә[10].

Мәчетләр һәм мөселман руханилары турында язганда гадәттә республика/өлкә архивларыннан Губерна идарәсе һәм Башкортстан Республикасы Милли архивында саклаучы «Оренбургское магометанское духовное собрание» фондыннан киң файдаланалар. Г. Хисамиев «Кыр Шонталасы авылы. Мәчетләр һәм дин әһелләре: Фәнни популяр басма» хезмәтендә, бу фондлардан тыш, Чистай өязе полиция идарәсе (245 ф.), Чистай өязе беренче һәм икенче стан приставлары (248 һәм 249 фондлар), Россия дәүләт борынгы актлар архивының ландрат һәм ревизия кенәгәләре (350 ф.) һәм Казан губернасы буенча Җир ызанлау канцеляриясенең төбәк җир ызанлау оешмаларының генераль һәм махсус җир ызанлау материаллары (1312 ф.) фондлары документларын

да җәлеп иткән. Шул рәвешле 17 руханиның нәсел-нәсәбе хакында шактый тулы мәгълүмат туплый алган. Бу исә, үз чиратында, китапны тематик яктан ике өлешкә – авыл мәчетләренең патша заманы, совет чоры һәм хәзерге көнгә караган аерым сәхифәләренә[11] һәм «кушымта» сыйфатында бирелгән руханилар биографияләренә[12] бүләргә мөмкинлек тудырган. Документларның тулы текстларын урнаштыру бик урынлы: чөнки йогынтылы төркем вәкилләренең руханилар өстеннән язган әләкләренә, алар арасындагы каршылыкка, Кыр Шонталасыннан килгән шикаятьләрне тикшерү эшләренә автор бәяләмәсе, гаепләләрне һәм дөреслекне ачыкларга омтылуы укучыга, рәсми кәгазьләр белән танышып, үзе фикер тупларга ярдәм итә. Шулай да, руханилар биографияләрен урнаштырганчы, мөселман дин әһелләренең мәхәлләдәге иҗтимагый тәртипне тәэмин итүдә, үсеп килүче буынга әхлак тәрбиясе бирүдә, дини тормышка җитәкчелек итүдә, кешеләрнең гаиләдәге, шатлык-кайгыларына бәйле вакыйгаларда катнашуы хакында махсус бер бүлек соралып тора.

Автор, «Экстракт в Правительствующий Сенат ис Казанской губернии о татарских мечетях» исемле документта туган авылында мәчет 60 ел элек салынган дигән сүзне игътибарга алып, беренче мәчет 1686 елда төзелгән дигән ялгыш фикер әйтә[13]. Мәчетләр тарихы турында чыганаклар, нигездә, губерна идарәсе күзәтүендә гыйбадәт кылу бинасы төзергә рөхсәт алу кәгазьләре, мәчетнең планы, төзү урыны планы, искергән бинаны ремонтлау яки реконструкция ясау белән бәйле документлардан гыйбарәт. Автор бу кәгазьләрне тиешенчә файдаланган, күп генә документларның фотокопияләрен яки күчермәләрен китергән. Материал, нигездә, мәчет биналарын төзү, мәчет бинасының януы, бинаны башка максатта файдалана башлау, манарасын кисү кебек темалар белән чикләнә. Бу бүлекне мәхәллә, мәчетнең дини бәйрәмнәр һәм көндәлек тормыштагы роле, абыстайлар институты, мәчет каршындагы мәктәп турында материаллар баетыр иде.

Хисамиев язган китаплар арасында XVIII-XX гасыр башына кадәр чорны колачлаган, күпсанлы архив чыганаклары һәм әдәбият кулланып язылган, фотолар белән баетылган хезмәт «Кыр Шонталасы авылының борынгы тарихы» дип атала.

Автор булачак авыл урынына күчәргә рөхсәт сорап язылган 1722 елгы һәм башка документларны җентекләп анализлап, яңа урынга урнашырга рөхсәт сорап гариза бирүчеләрдән Иске авылда (хәзерге Урманасты Шонталасыннан бер чакрым ераклыкта урнашкан борынгы авыл), Нарат Елга һәм Шонтала авылында яшәүчеләр нигез салганын ачыклый. Авылда сакланган риваятьләр буенча, Кыр Шонталасына татар-мөселманнардан тыш, төрле елларда берничә чуаш һәм мукшы халыклары вәкилләре килеп урнашкан[14], бергә яшәп, алар татарлашканнар. Ревизия кенәгәләрен өйрәнеп, автор бу риваятьләрнең чынбарлыкка туры килгәнен раслый. «Шонтала» сүзенең этимологиясен мукшы һәм татар телләренә бәйләп анализлый, ахырдан галимнәр Ф. Гарипова һәм Г. Саттаров фикерләре нигезендә «Шонтала – дала елгасы» дигән версиягә өстенлек бирә[15].

Г. Хисамиев татарларны чукындыруның дүрт этабын билгели (1552 елдан соң; XVIII гасырның беренче яртысы; 1825-1855 еллар; XIX гасырның икенче яртысыннан 1917 елга кадәр), һәм туган авылы тарихын да шушы кысаларда бәян итә[16]. Авыл халкының бер өлеше 1747 елда чукындырылганын дәлилли, күрше




авылларда да шундый вакыйгалар булганын әйтеп үтә[17]. Китапның беренче кисәгендә елгалар, күлләр, болыннар, урманнар, зиратлар турында бүлек, 1886 елгы план буенча авыл төзелеше һәм башка материаллар урнаштырылган.

Икенче кисәктә «яңа чукындырылганнарның» 1905-1906 елларда җиңү белән тәмамланган ислам диненә кайту өчен көрәше, төбәк, аерым очракларда Казан губернасында шуңа охшаш вакыйгаларга күзәтүләр ясап, бәян ителә.

Өченче «Төрлесеннән» дип аталган кисәктә авыл җәмгыятендә төрле вазифалар (авыл старостасы, полиция сотнигы, полиция десятнигы, янгын һәм кыр каравылчылары) башкарган кешеләрнең исемлекләре бирелә, шулай ук авыл җирлегендә табылган чүлмәк ватыклары, империя чорында сугылган акчалар, бик борынгы тарихи чор таш эш кораллары сурәтләнә. Авыл кешеләренең кушаматларына багышланган бүлек тә бик җиңел укыла. Метрикә кенәгәләре, авыл җыеннары карарларыннан бөртекләп җыелган нәсел тамгаларын, мөселманлыкка кайткан авылдашларын да читләтеп үтмичә урнаштыру авторның уңышы булып саналырга лаек.

Күпсанлы архив чыганакларына нигезләнеп язылган «Кыр Шонталасы тарихы: Мәхшәр еллар: документаль-әдәби басма»[18] исемле китабы төрле бәлаказаларга, җәмгыятьне тирәнтен сынаган һәм тетрәндергән вакыйгаларга багышланган очерклар циклыннан гыйбарәт. Хезмәтнең беренче бүлеге 1892 елны төбәктә таралган холера авыруына каршы көрәшне тасвирлый.

Икенче бүлектә 1917 елда, патша бәреп төшерелгәч, төбәк крестьяннарының җирле алпавытлар белән «яңача» мөнәсәбәт коруы, 1918 елда авыл ярлылар комитетларының эшчәнлеге, 1918 елда исемнәре авыл советлары итеп үзгәртелгәч, аларның Гражданнар сугышы елларында аграр һәм продразверстка, салымнар җыю, җәмәгать тәртибен саклау сәясәтен тормышка ашыру буенча эшчәнлеге, 1919-1924 еллардагы дәһшәтле ачлык вакытында авыл халкының тормышы һәм көнкүреше сурәтләнә.

«Төрлесеннән» дип аталган өченче бүлектә урнаштырылган очеркларда 1923 елда төбәктә авыл кырларында саранча белән көрәш, Кыр Шонталасында ачылган совет мәктәбе тарихы һәм укый-яза белмәүчелекне бетерү кампаниясе (1917-1928 еллар), 1920 елда совет хакимияте вәкилләренең тоз белән спекуляция ясауда гаепләнү вакыйгасы, совет хакимияте урнашкач төбәк тормышында мөһим роль уйнаган җитәкчеләрдән Кызылъяр волосте рәисе Гаяз Садыйков (1919-1922), авыл советы рәисе Н. Гатауллин, элекке комбед рәисе И. Абрамов турында хикәяләнә. Чистай өязе ат караклары (1880-1890 еллар) һәм Кыр

Шонталасы авылы кешеләренә карата хакимият органнарында кузгатылган эшләр дә архив чыганакларына таянып ачыкланган.

Гомумән алганда, тарихи вакыйгалар Кызылъяр волосте (1924 елдан Алексеевск волосте), аерым урыннарда Чистай һәм күрше кантоннар, Татарстан Республикасы масштабында тасвирлана. Текстның шактый зур өлеше киләчәктә төгәлләштерелгән авыллар тарихын язу өчен материал кебек кабул ителә.

Бу хезмәттән аермалы буларак, Г. Хисамиевның 2016 елда дөнья күргән «Кыр Шонталасы: Михнәтле (1928-1961) еллар: фәнни-популяр басма»[19] исемле күләмле китабында сүз фәкать Бөек Ватан сугышы алдыннан һәм аннан соңгы елларда авыл советының кыңгыр эшчәнлеге, шушы җирлектә оештырылган Вахитов исемендәге күмәк хуҗалыкта хезмәт дисциплинасының торышы, крестьяннарның игенчелек, кырчылык, терлекчелектә фидакарь хезмәте, икмәк, ит, сөт, йон, йомырка җитештерү буенча дәүләт планнарын үтәүгә керткән тырышлыклары, мәктәп, уку йорты (изба-читальня), медицина пункты, җирле партия һәм комсомол оешмасы, шулай ук авылдашлары – репрессия корбаннары турында бара.

Автор тексты төрле оешмаларның эш кәгазьләре, шул исәптән авыл советы сессияләре, күмәк хуҗалык идарәсе, күмәк хуҗалыкның башлангыч партия оешмасы утырышлары беркетмәләреннән өзекләр, нигездә район газетасында басылган күпсанлы язма-хәбәрләр, өлкән буын кешеләренең хатирә-истәлекләре белән «ныгытылып», беркетелеп бара.

«Кыр Шонталасы авылы тарихы: Хәтер китабы»[20] басмасының төп яңалыгы – Бөек Ватан сугышы/Икенче бөтендөнья сугышында катнашкан шәхесләр белән чикләнмичә, хәрби хезмәттә булганнарны XVIII гасырдан башлап барлаудан гыйбарәт. Китапта Кыр Шонталасыннан рекрут хезмәтенә алынучылар – 1762-1858 еллардагы ревизия материалларын, 1874 елда кертелгән гомуми хәрби бурычны үтәүчеләр – төрле хакимият оешмалары кәгазьләрен, Беренче бөтендөнья сугышында катнашучылар нигездә интернеттагы «Герои Первой мировой войны» исемле сайт материалларын һәм архив чыганакларыннан өйрәнеп башкарылган. Автор Беренче бөтендөнья сугышында 92 кеше мобилизацияләнгәнен, шуларның 12 әсир төшкәнен, күбесенең туган җиргә әйләнеп кайтканын раслаган. Шулай ук Гражданнар сугышында кимендә 76 авылдашы катнашканын, араларында дезертирлар булганын да ачыклаган.

Г. Хисамиев «Память народа» сайтына куелган материалларны өйрәнеп һәм хаталарны ачыклап, Икенче бөтендөнья сугышында катнашкан 131 авылдашының исем-фамилиясен төгәлләштергән, һәрберсе турында кыскача мәгълүмат, фотосын һәм аңа кагылышлы «Память народа» сайтыннан документ яки аның текстын урнаштырып барган. Бер очтан, булдыра алганча, авылдашларының Кыр Шонталасындагы « Аларга мәңгелек дан» дигән обелискка язылган исем, фамилияләрен язганда җибәрелгән хаталарны да төзәткән. Китапта тыл батырларының исемлеге ике томлык «Герои тыла Республики Татарстан. Алексеевский район» (Казань: Книга памяти, 2020) исемле китап буенча тергезелгән.

Автор совет хакимияте тарафыннан төрле дәрәҗәдә репрессияләнгән 70 кешенең исем-фамилиясен ачыклаган.

«Тыныч хезмәт алдынгылары» исемлегенә Кыр Шонталасының хөкүмәт бүләкләренә лаек булган 102 кешесе кертелгән, ә авылдан чыккан галимнәр исемлегендә ике фәннәр докторы һәм алты фәннәр кандидаты аталган.

«Хатирәләр. Шонталалылар иҗаты» исемле соңгы бүлектә сугыш темасына һәм сугыш чорындагы авыл тормышына кагылышлы материаллар (истәлекләр, мәкаләләр, шигырьләр) урнаштырылган.

Йомгаклап әйткәндә, чыганаклары төгәл күрсәтелеп барылган бу хезмәт тарихи хәтерне яңартучы, Кыр Шонталасы авылы ир-егетләре батырлыгына һәйкәл буларак кабул ителә.

Г. Хисамиев «Гөләйза кыйссасы», «Кыр Шонталасы тарихы: Мәчетләр һәм дин әһелләре: фәнни-популяр басма», «Кыр Шонталасы тарихы: Мәхшәр еллар: документаль-әдәби басма» исемле китапларын документаль басмалар дип атый. Шул рәвешле бу басмаларда күпсанлы чыганаклардан өзекләр китерелгәнен ассызыклый.

Авторның документаль басмалары исемлегенә югарыда карап үткән «Кыр Шонталасы тарихы: Михнәтле (1928-1961) еллар», «Кыр Шонталасы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (тулы вариант)», «Кыр Шонталасы авылы тарихы: Хәтер китабы», шулай ук автор апасы Фәйрүзә Хисамиева белән бергә төзегән, XX гасыр уртасыннан алып бүгенгәчә авылдашлары, шул исәптән үзләре дә иҗат иткән, төрле жанрга караган язмалар, алты бәет тупланган «Йөрәкләр авазы: Кыр Шонталасы авылының халык иҗаты» (Казан, 2016)[21] басмасы да карый.

Шул рәвешле, Г. Хисамиев туган авылы турында күләме 150 басма табактан арткан, микротарихи анализга нигезләнгән документаль фәнни-популяр монографияләр бастырып, төбәк тарихын өйрәнүне яңа дәрәҗәгә күтәрде, авыл тарихлары язуда архив чыганакларының яңа мөмкинлекләрен күрсәтте.

Мондый документаль басмаларның башка төбәк тарихына багышланган хезмәтләрдән өстенлеге – аерым шәхесләрнең биографияләрен, вакыйгаларны, оешмалар, торак пунктлары тарихын җентекләп, мөмкин кадәр тулы итеп һәм һәрьяклап тасвирлау мөмкинлеге бирүдән гыйбарәт.

Г. Хисамиев китапларының икенче, нигездә автор текстыннан торган, төркемен фәнни-популяр басмалар дип атау урынлы булыр. Бу исемлеккә инде карап үткән китаплардан «Гөләйза кыйссасының» икенче басмасы, «Кыр Шонталасы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (кыскартылган варианты)», «Кыр Шонталасы авылының борынгы тарихы» керә.

Автор, бер авыл тарихы буенча аерым хронологик кысаларда һәм аерым темаларга китаплар язып, төбәкне өйрәнү өлкәсенә зур өлеш кертте. Кыр Шонталасының тарихындагы якты һәм караңгы якларны, авылдашлары кылган яхшы һәм тискәре гамәлләрне бер үк дәрәҗәдә объектив рәвештә ачкан Хисамиев Галим Гыйльметдин улына киләчәктә яңа иҗади уңышлар телибез. Аның төбәк тарихы белән шөгыльләнүчеләр өчен үрнәк булырлык яңа хезмәтләрен көтеп калабыз.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**

1. *Хисамиев Г. Г.* Гөләйза кыйссасы. – Казан: Отечество, 2015. – Б. 4-113.
2. Шунда ук. – Б. 114-119.
3. Шунда ук. – Б. 111.

4. *Хисамиев Г. Г.* Гөләйза кыйссасы: Фәнни-популяр басма. Икенче басма. – Казан: Вестфалика, 2021. – Б. 61-71.
5. Татар хатыны ниләр күрми // Хисамиев Г. Г. Гөләйза кыйссасы. – Казан: Отечество, 2015. – Б. 120-286.
6. Шунда ук. – Б. 285.
7. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (тулы вариант). – Казан: Отечество, 2021. – Б. 3-4.
8. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы авылының борынгы тарихы. – Казан: Вестфалика, 2025. – Б. 190-200.
9. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (кыскартылган варианты). – Казан: Отечество, 2021. – 132 б.
10. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Гаилә шәҗәрәсе. – Казан: Отечество, 2021. – 48 б.
11. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Мәчетләр һәм дин әһелләре: фәнни-популяр басма. – Казан: Отечество, 2015. – Б. 6-26.
12. Шунда ук. – Б. 27-380.
13. Шунда ук. – Б. 6.
14. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы авылының борынгы тарихы... – Б. 11-14.
15. Шунда ук. – Б. 30-31.
16. Шунда ук. – Б. 73.
17. Шунда ук. – Б. 86.
18. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Мәхшәр еллар: документаль-әдәби басма. – Казан: Вестфалика, 2018. – 278 б.
19. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Михнәтле (1928-1961) еллар: фәнни-популяр басма. – Казан: Вестфалика, 2016. – 267 б.
20. *Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы авылы тарихы: Хәтер китабы. – Казан: Вестфалика, 2023. – 375 б.
21. Йөрәкләр авазы: Кыр Шонталасы авылының халык иҗаты / Төз.-авт.: *Ф. Г. Хисамиева, Г. Г. Хисамиев.* – Казан: Отечество, 2016. – 307 б.

## Әдәбият исемлеге

Йөрәкләр авазы: Кыр Шонталасы авылының халык иҗаты / Төз.-авт.: *Ф. Г. Хисамиева, Г. Г. Хисамиев.* – Казан: Отечество, 2016. – 307 б.

*Хисамиев Г. Г.* Гөләйза кыйссасы. – Казан: Отечество, 2015. – 286 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Мәчетләр һәм дин әһелләре: фәнни-популяр басма. – Казан: Отечество, 2015. – 285 б.

Хисамиев Г. Г. Кыр Шонталасы тарихы: Михнәтле (1928-1961) еллар: фәнни-популяр басма. – Казан: Вестфалика, 2016. – 267 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Мәхшәр еллар: документаль-әдәби басма. – Казан: Вестфалика, 2018. – 278 б.

*Хисамиев Г. Г.* Гөләйза кыйссасы: Фәнни-популяр басма. Икенче басма. – Казан: Вестфалика, 2021. – 71 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (тулы вариант). – Казан: Отечество, 2021. – 413 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Шәҗәрәләр китабы (кыскартылган варианты). – Казан: Отечество, 2021. – 132 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы тарихы: Гаилә шәҗәрәсе. – Казан: Отечество, 2021. – 48 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы авылы тарихы: Хәтер китабы. – Казан: Вестфалика, 2023. – 375 б.

*Хисамиев Г. Г.* Кыр Шонталасы авылының борынгы тарихы. – Казан: Вестфалика, 2025. – 223 б.

## References

*Jorekler avazy: Kyr Shontalasy avylynyn halyk ijjaty toz.-avt.: F. G. Hisamieva, G. G. Hisamiev* [The Call of hearts: folk art of the village of Polevaya Shontala. Compiled by: F. G. Khisamieva, G. G. Khisamiev]. Kazan: Otechestvo publ., 2016, 307 p.

Hisamiev G. G. *Golejza kyjssasy* [Guleiza's Story]. Kazan: Otechestvo publ., 2015, 286 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy tarihy: Mechetler hem din ehellere: fenni-populyar basma* [The history of the field chantal: mosques and religious figures: a popular science publication]. Kazan: Otechestvo publ., 2015, 285 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy tarihy: Mihnetle (1928-1961) ellar: fenni-populyar basma* [The history of the field Chantal: difficult (1928-1961) years: popular science edition]. Kazan: Vestfalika, publ., 2016, 267 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy tarihy: Mehshər ellar: dokumental'-edebi basma* [The history of the field umbrella: a documentary and literary publication]. Kazan: Vestfalika publ., 2018, 278 p.

Hisamiev G. G. *Golejza kyjssasy: Fenni-populyar basma. Ikenche basma* [The History of the Gulag: a popular science publication. Second edition]. Kazan: Vestfalika publ., 2021, 71 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy tarihy: Shejereler kitaby (tuly variant)* [The history of the field umbrella: A Family Tree book (full version)]. Kazan: Otechestvo publ., 2021, 431 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy tarihy: Shejereler kitaby (kyskartylgan variant)* [The history of the field umbrella: A Pedigree book (abridged version)]. Kazan, Otechestvo publ., 2021, 132 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy tarihy: Gaile shejerese* [The history of the field umbrella: The genealogy of the family]. Kazan: Otechestvo publ., 2021, 132 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy avyly tarihy: Heter kitaby* [The history of the village of Polevaya Shontala: The Book of Memory]. Kazan: Vestfalika publ., 2023, 275 p.

Hisamiev G. G. *Kyr Shontalasy avylynyn boryngy tarihy* [The ancient history of the village of Polevaya Shontala]. Kazan: Vestfalika publ., 2025, 223 p.

## Сведения об авторе

***Загидуллин Ильдус Котдусович,*** доктор исторических наук, доцент, главный научный сотрудник Центра исламоведческих исследований АН РТ, e-mail: zagik63@mail.ru

## About the author

***Ildus K. Zagidullin,*** Doctor of Historical Sciences, Associate Professor, Chief Research Fellow at the Center for Islamic Studies, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, e-mail: zagik63@mail.ru

## В редакцию статья поступила 29.01.2026, опубликована:

*Загидуллин И. К.* Төбәк тарихын өйрәнүче Г. Г. Хисамиев хезмәтләре // Гасырлар авазы – Эхо веков Echo of centuries. – 2026. – № 3. – Б. 98-108.

## Submitted on 29.01.2026, published:

Zagidullin I. K. *Tobek tarikhyn oirenyche G. G. Khisamiev khezmetlere* [Works of local historian G. G. Khisamiev]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov* [Echo of centuries], 2026, no. 3, pp. 98-108.